**Тема:** Акыллы кеше- Аллаһны таныган кеше.

**Максат:**
1. Акыллы кешенең гомере кеше хаталарын өйрәнүгә китүен аңларга ирешүе.
2. Акыл – бөек хәзинә икәнлеген исбатлау.
3. Акыл турында халык әйтемнәре, мәкалләре белән таныштыру.
4. Чын акыллы кеше- Аллаһны таныган кеше икәнен аңлату.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**
- Аллаһы Тәгалә кушканче яшәү- акыллы, бәхетле кешенең юлы икәнен аңлау.
- Акыллы кешенең иң кирәкле сыйфатларның берсе- үз язмышыңа риза булу, Аллаһка шөкер итү икәнең аңлау.
- Акыллы кешегә бирелгән киңәшләрне тырмышка ашырырга теләк уяту.

**Эпиграф:**
- *"Акыллы кеше үз кимчелегенә ачынмый (артык кайгырмый), бәлки үзенә дөрес нәтиҗә ясый. Начарлык эшләдең икән, шунда ук яхшылык кол, чөнки синең кылган яхшылыгың ул начарлык юлын каплый".*
- *Нәрнәрсәнең зәкяте бар. Акылның зәкяте ахирәтне уйлауда.*

*/ Локман Хәким/*

**Дәрес барышы**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**
- Кечкенә генә хикәяне тыңлагыз, шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез:

*Акыл иясе булган Сөләйман патша янына ике ана килгән. Хатыннар берүк йортта яшәгәннәр. Аларның икесендәдә бер яшьтәге ир балалары булган. Бер ана узган төндә баласын таптап үтергән дә , аны икенче хатын янына салып, исән баланы үзе янына алган һәм: "Бала минеке",- дип дәгъвәләгән. Икенче хатын бу сүзләр- бары тик ялган дип тукып тора. Аналар бер- берсен алдауда гаеплиләр.*

*Сөләймән патша колычны алып килеп, аның белән баланы чабарга һәм яртысын бер анага, яртысын икенче анага бирергә куша. Чын ана елый башлый, борчыла, улын исән килеш үзенә бирүен үтенә. Ә икенчесе: "Миңа булмагач, аңа да булмасын!" – дип, чабарга рөхсәт итә.*

*Шулай итеп Сөләймән патша чын ана улын исән калдырырга үтенгән хатын икәнен ачыклый һәм баласын үзенә бирдерә.*

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**
Димәк, бүгенге дәреснең темасы... (Акыллы кеше турында)

**III. Уку мәсьәләсен чишү.** ***Төркемнәрдә эшләү.***
**1нче бирем Уен *"Мин башлыйм, син дәвам ит"***
(Тәрбияче башлый, укучылар дәвам итәләр).
- Хәзер уен уйнап алыйк! Сыйфатларны мин әйтә башлыйм- сез дәвам итәрсез.
1. Акыллы, яхшы кешеләр белән генә ... *аралаш, дус бул.*
2. Бәхәстән, тарткалашудан ... *ерак булырга тырыш.*
3. Кешеләрнең начар холыкларын ... *кичерә бел.*
4. Ачык өйзле, елмаючан ... *булырга тырыш.*
5. Дошманлык хисләр синнән ... *ерак булсыннар.*
6. Кеше кимчелеген эзләп, тикшереп гомереңне ... *әрәм итмә.*
7. Беркайчанда ... *зарланма.*
8. Үзеңдә матур, үрнәк холык ...*тәрбияләргә тырыш.*
9. Кешеләр белән аралашканда "кирегә сукалама", сүз саен ... *каршы килмә.*

10. Кешене гаепләгәнче- барысында ... *төшен.*
11. Синнән сорамаганда, сиңа кагылмаган эшкә ... *"тыгылма".*
12. Үзеңне генә түгел, башкаларныда ... *"тыңлый, ишетә" бел.*
13. Үзеңне кешеләрдән акыллырак итеп ... күрсәтергә торышма, син генә һәрвакыт дөрес дип ... исәпләмә.

**2нче бирем** ***"Хаталарны ничек ясамаска?"***
- "Хаталарны ничек ясамаска?" дигән сорауга җавап табып карыйк әлә.
/Укучылар җаваплары/

**3нче бирем бирем** ***"Чагыштырыйк әле!"***
- Сезнең җавапларыгызны безнең фикерләр белән чагыштырыйк:
- Эшкә тытынганчы, ныклап уйла- нәтиҗәсен күз алдыңа китер.
- Әти- әниләр, укытучылар, дуслар белән киңәшләш.
- Эш өчен җаваплы кеше буларак, карарны үзең кабул ит.
- Хаталарыңны таный бел һәм вакытында төзәт.
- Хаталарыңны күрсәткән кешегә үпкәләмә- төзәтергә тырыш.
- Үз хаталарыңны кабатламаска торыш.
- Кешеләрне күзәт- аларның хаталарында кабатлама.

**4нче бирем** ***"Хикмәт иясе чын акыллы кешенең 10 сыйфаты"***
*Акыллы кеше...*
- Аллаһ Тәгаләгә ышана, бөтен эшендә Аңа таяна.
- Дөньясын алып барганда, ахирәтенә кимчелек китерми, ахирәтен алып барганда, дөньясын да онытмый.
- Изгелекне ярата, гөнаһлардан, файдасыз эшләрдән тыела.
- Начарлыкка начарлык белән җавап бирми.
- Ачуландырсалар- ачу сакламый.
- Акыллы сүзне игътибарсыз калдырмый, файдалы киңәш бирергә саранланмый.
- Дөньяга һәм ахирәткә кагылышлы файдалы эшләргә ялкаулык күрсәтми.
- Булганның кадерен белә, сынаулар килсә, зарланмый.
- Кешеләрдә булган уңышларга карата хөсетләнми (кенләшми).
- Туганнарын, дусларын, күршеләрен хөрмәт итә, игелек күрсәтә.
- Аллаһ Раббыбыз хакыкый бәхетне дин эченә яшерде. Кем Аллаһы Тәгаләне таныды- Ул кушканны үтәп, тыелганнан тыелды- акыллы кеше, чөнки аны мәңгелек җәннәт көтә.

**5 бирем** ***"Акыллы кешенең кыйммәтле сөрләре"***
- Фикернең төп элешен без әйтеп китәбез, сез аны испатлап дәвам итәрсез. Ни өчен шулай дип үз фикерегезне өстәрсез.
1. *Бары тик әдәпле, намуслы кешеләр белән генә аралаш*, чөнки... Аларга ышанып була. Аларның намуслары- чын таяныч.
2. *Дуслар белән ярышма- дошманлашудан саклан*, чөнки... Сизми калырсың- дустың дошманга әйләнер.
3. *Кайбер холыксыз кешеләрнең дорфалыкларына түзәргә туры килә*, чөнки... Аларны үз тормышыңнан алып атып булмый икән- алар белән дә килешә белергә кирәк.
4. *Ачык йөзле булырга омтыл*, чөнки.... Яхшы күңелле кешеләр сиңа тартылырлар. Тәккәберләрне беркем дә яратмый.
5. *Ачуланып, ызгышып- талашып йөрүдән ерак бул*, чөнки... Тыныч яшисең килсә, усалланма.
6. *Кеше хаталарын җыю, тикшерү белән мавыкма*, чөнки... Башкаларның гөнаһларын эзләгән кешенең күңеле керләнә.

7. *Зарланудан ерак бул*, чөнки.... Акыллы кеше үпкәсен сиздермәс, яхшылыкны искә алыр.
8. *Яхшы холыклы бул*, чөнки... Эчке доньяңның матурлыгы- синең мәңге бетмәс байлыгың.
9. *Гел каршы килеп, үз фикеремне әйтәм дип, кирегә сукалама*, чөнки... Кире, акылсыз кеше дип дан булырсың.
10. *Үзеңне башкалардан акыллырак итеп күрсәтергә тырышма- тыйнак бул*, чөнки... Буш сүз- әрәм вакыт.
11. *Ярдәм сорамаганда, кеше эшенә тыгылма*, чөнки... Үзләре хәл итәрләр.
12. *Үзең генә сөйләмә- башкаларны тыңларга өйрән*, чөнки... Кешеләр сине яратырлар.

**6нче бирем *“Акыллы кешенең 13 киңәше”***
- Киңәшне дәвам итегез.
1. Акыллы кеше күбрәк тыңлап тора, әзрәк ... сөйләшә.
2. Акыллы кеше бөтен ситуациядә башта “плюсларны” ... эзли, аннары “минусларны” ... исәпли.
3. Акыллы кеше күңелендә булганын башкаларга ахырына кадәр ... ачмый.
4. Акыллы кеше белемен кайчан һәм ничек итеп кулланырга икәнен ...яхшы белә.
5. Акыллы кеше башка кеше белән булган проблемаларын үзе ... хәл итәргә тырыша, 3нче кешене ... катнаштырмый.
6. Акыллы кеше башкаларны ... гаепләми, хурламый.
7. Акыллы кеше гаепне, үземдә түгел микән ...дип уйлый.
8. Акыллы кеше һәр эшкә бар көчен ... кулланып эшли.
9. Акыллы кеше башкарасы эшкә алдан ... әзерләнә, аны планнлаштыра, булачак авырлыкларга ... әзер була.
10. Акыллы кеше башкаларның фикерен ... тыңлый, үзенчә ... эшли. Үз фикере ялгыш икәненә төшенсә- аны ... дөресли, үзгәртә.
11. Акыллы кеше Аллаһы Тәгалә биргән мөмкинлекләрне кулдан ... очкындырмый, белемен, сәләтен ... куллана.
12. Акыллы кеше аңа бирерлгән саулыкның ... кадерен белә.
13. Акыллы кеше уңышсызлыкларны уңай тәҗрибә итеп ... кабул итә.

**7нче бирем *“Танылган шәхескә сүз бирик”***

Кайчандыр кол булган, аннан соң азат ителгән Локман Хәкимгә хикмәт (акыллылык) бирелү тарихын искә төшерик.

*Аллаһ Раббыбыз Үзенең фәрештәләре аркылы аңа пәйгамбәрлек һәм хәлифә (патша) булуны тәкъдим итә. Локман Хәким: “Сайлау мөмкинлеге бармы?” - дип сорый. Уңай җавап алгач, икесеннән дә баш тартып: “Миңа бәлаләрдән сәламәтлек, кирәк. Пәйгамбәрләргә пәйгамбәрлек белән бәла килгәнен беләмен... Әгәр дөрес хөкем итсә, хуш. Әмма золым кылса, урыны җәһәннәм. Миңа дөньяда түбәнлек, хурлык кылынып, ахирәттә газиз булу артыграк”, - ди.*

Пәйгамбәрлек һәм патшалыкка караганда гади кеше булуны артык күргәне өчен Аллаһ Раббыбыз аңа гыйлем һәм хикмәт бирә... Локман Хәким турында бер хикәяне тыңлап китик:

*Локман Хәким кол вакытта хуҗасы аны бакчасына җимеш җыярга җибәрә. Барлык коллар күп итеп җимеш ашый, ләкин Локман Хәким ашамый. Рөхсәтсез ашаган җимеш хәрәм була, калебне каралта, ихтыяр көчен бетерә.*

*Юләрләр арасында бер акыллы булса, юләрләр аны диванага чыгарып көлә. Коллар да Локман Хәкимнән көлгән һәм кайткач сүз берләшеп: “Ул җимеш ашады”, - дип хуҗага җиткергән. Бар шаһитлар да Локман Хәкимгә каршы. Хуҗасы ачуланып: “Сиңа нинди җәза бирим?” - дигәч, Локман Хәким: “Син барыбызга да күп итеп җылы су эчер, аннан йөгерергә мәҗбүр ит, хакыйкатьне күрерсең”, - дигән.*

*Күп итеп җимеш ашаучыларның барысы да йөгергәндә коскан, Локман Хәкимнең генә су чыккан. Хуҗа эшнең ни икәнен аңлаган. Локман Хәким зарланмаган, әләкләмәгән, хәтта акланмаган да, үзенең зирәклеге белән кыен хәлдән чыккан.*

- Локман Хәким улына бер капчык гәрчич орлыгы санынча нәсыйхәт-киңәшләр биргән икән. Аларны санап-язып бетерү мөмкин түгел. Монда кайберләрен генә әйтеп китәбез. Танылган шәхеснең нәсыйхәтләрен ничек итеп аңлыйсыз?

- *Кешенең кыяфәтенә түгел, акылына карарга өйрән.*
- *Утны утын яндырып торган кебек, акылыңны да әдәп белән кыздырып тор.*
- *Акыллы булу бай булудан өстен, байлык бетәргә мөмкин, акыл кала.*
- *Локман Хәкимнән сораганнар: "Син кемнән әдәплелелеккә өйрәндең? – " Әдәпсезләрдән",-диеп җавап биргән ул. - Берәүдә ярамаган эш яки гәдәт күрсәм, бу сыйфат миндә юк микән, дип, төзәлергә тырыштым ."*
- *Нәрнәрсәнең зәкяте бар. Акылның зәкяте ахирәтне уйлауда.*
- ***Акыллы кеше үз кимчелегенә ачынмый (артык кайгырмый), бәлки үзенә дөрес нәтиҗә ясый. Начарлык эшләдең икән, шунда ук яхшылык кол, чөнки синең кылган яхшылыгың ул начарлык юлын каплый.***

- Бу сүзләрне бүгенге дәреснең эпиграфы итеп алдык. Аны ничек итеп аңлыйсыз?

**8 нче бирем** ***"Акыллы кешенең тагын бер сыйфаты"***

- Коръәндә Локман Хәкимгә багышланган бер сүрә бар- "Локман" сүрәсе. Аллаһ Раббыбыз Коръәни-Кәримдә ("Локман" сүрәсе, 11 нче аять) әйтә: *"Хактыр ки, Без Локманга, Аллаһка шөкер ит, дип хикмәт (ачык зиһен, зирәклек) бирдек. Шөкер иткән кеше үзе өчен шөкер итәр. Шөкер итмәгән кеше - шөкер итмәсен - Аллаһ аның шөкеренә мохтаҗ түгел. Аллаһ һәртөрле мактауга лаек*".

Акыл, хикмәт – зирәклек ул - Аллаһ биргән акылың ярдәмендә, алган гыйлемеңне тормышта дөрес итеп куллана һәм башкаларга җиткерә белү. Без үзебезне иманлы кеше дип саныйбыз, күбрәк изгелек кыласыбыз, савап җыясыбыз килә. Риваятьләрдә килә, Муса (г-м) Аллаһтан: "Син риза булсын өчен, рәхмәтеңә ирешү өчен нәрсә эшлим?" - дип сораган һәм Аллаһ Раббыбыз: "Бу бик җиңел, Мин биргән язмышыңа канәгать бул һәм шөкер ит", - дигән.

- Димәк акыллы кешенең тагын бер сыйфаты- үз язмышыңа риза булу, шөкер итү.

**IV. Рефлексия (Йомгаклау).**

- Дәреснең темасын искә тешерегез.
- Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз?
- Акыллы кеше Аллаһ Тәгаләгә ышана, бөтен эшендә Аңа таяна.
- Хаталарыңны таный бел һәм вакытында төзәт.
- Хаталарыңны күрсәткән кешегә үпкәләмә- төзәтергә тырыш.
- Үз хаталарыңны кабатламаска кирәк. Кешеләрне күзәт- аларның хаталарын кабатлама.)
- Нәркемнең бәхетле буласы килә. Әммә иң зур бәхет- Аллаһны тану һәм доньяда Ул кушканча яшәү, туры юлдан бару. Ә монсы инде чын акыллы кешенең юлы.
- Дәреснең эпиграфын искә төшерик. *("Акыллы кеше үз кимчелегенә артык кайгырмый, бәлки үзенә дөрес нәтиҗә ясый. Начарлык эшләдең икән, шунда ук яхшылык кол, чөнки синең кылган яхшылыгың ул начарлык юлын каплый").*
- Бу кайсы хикмәт иясенең сүзләре? Аларны ничек итеп аңлыйсыз?

**V. Өйгә эш: Өй эшен вариантлап бирәбез:**

1. "Акыллы кешенең кыйммәтле сөрләре?" дигән темага җавап әзерләп килергә.
2. "Аллаһны таныган акыллы кешенең яшәү рәвеше нинди була?" дигән темага җавап әзерләргә.